ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail:Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

№2 — 29 января 2021г.

### Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм 2020 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. 3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче /Р.К.Хафизов /

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.01.2021 ел, 2 нче санлы карарына
1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә җирләү буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы
вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2955,52 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 770,10 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2699, 36 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Җитәкче /Р.К.Хафизов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Ишки авыл
җирлеге Башкарма
комитетының
29.01.20210 ел, 2 нче санлы
карарына
2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 916,93 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2122,51 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 785,70 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2599,84 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Җитәкче /Р.К.Хафизов/